СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД ИННОПОЛИС»
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район, Республика
Татарстан, 420500

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ
«ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ»
СОВЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

РЕШЕНИЕ | КАРАР

07.04.2026 | № 12-66

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә билгеләнгәндә гражданнар үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазыйфаларының Исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлеген оптимальләштерү максатларында, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 25.06.2013 ел № 50-ТРЗ статьясына таянып, шулай ук «Коррупциягә каршы көрәш турында» 25.12.2008 ел № 273-ФЗ Федераль законның 8, 8.1 статьяларына таянып,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә билгеләнгәндә гражданнар үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр

тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы муниципаль хезмәтетвазыйфаларының Исемлеген  әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. «Гражданнар үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле һәм муниципаль хезмәткәрләр билгән очракта үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) керемнәре, мөлкәти характердагы чыгымнары һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында»  Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 25.11.2025 ел № 3-24 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге адрес буенча: http://verhniy-uslon.tatarstan.ru, һәм Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Иннополис шәһәре Мэры вәкаләтләрен вакытлыча башкаручы И.Р. Хуззятов

«Иннополис» шәһәре муниципаль
берәмлеге Советының
2026 елның 7нче апреленнән
№ 12-66 карарына
Кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә билгеләнгәндә граждannар үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазыйфаларының Исемлеге

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазифалары:

Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе

Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;

Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Иннополис шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары – торак-коммуналь хуҗалык, җир төзелеш, архитектура һәм төзекләндерү бүлеге начальнигы.

2. Муниципаль хезмәтнең төп вазифалары:

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының хокукый ярдәм бүлеге начальнигы;

Иннополис шәһәре Башкарма комитеты финанс бүлеге начальнигы.